**ГЛАВА АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 17 от 01.04.2019

# Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Иҗтимагый советы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында " 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга таянып карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгының «Социаль хезмәтләр күрсәтүче учреждениеләрнең эш сыйфатын бәяләүнең бәйсез системасын формалаштыру турында» 2016 елның 28 июлендәге 41 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иҗтимагый советы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

2.2 пунктта түбәндәге эчтәлекле унынчы абзац өстәргә::

“- коррупцияне кисәтүгә һәм аңа каршы торуга юнәлдерелгән чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру.”.

2.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л. Р. Сафинга йөкләргә.

**Район башлыгы вазифаларын башкаручы** **Л. Т. Хантимиров**